Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Кәркәүч авыл җирлеге Советы

КАРАР

27 март, 2024 ел № 10

Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Ташлы-Елга авылы торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Ташлы-Елга торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы Ташлы-Елга авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кәркәүч авыл җирлеге Уставы нигезендә,Кәркәүч авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 8 апрелендә 15 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Ташлы-Елга торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы Ташлы-Елга авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеның беренче этабын үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Ташлы-Елга авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Кәркәүч авыл җирлеге Ташлы-Елга авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, экскаватор белән траншея эшләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре;

- юлларны кардан чистарту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; башка эш төрләре;

- урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре;

- җәен юлларны карап тоту, җәен территорияне чабу, табигый туфракта куаклар һәм вак урманлыкларны төпләү проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; башка эш төрләре;

- Ташлы Елга авылы чишмәсен төзекләндерү, карап тоту һәм ремонтлау, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү, карап тоту һәм ремонтлау буенча башка эш төрләре;

- су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суыртү манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, янгын гидранты һәм тирәннән суыртү насосы сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суыртү манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре;

- яр буе зоналарын карап тоту һәм чистарту, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, башка эш төрләре;

- зират территориясен карап тоту һәм төзекләндерү, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; башка эш төрләре.

2023 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

- урам яктыртуны ясау (урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суыртү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суыртү манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, янгын гидранты һәм тирәннән суыртү насосы сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суыртү манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, экскаватор белән траншея эшләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- торак пункт территориясен төзекләндерү ( юлларны кардан чистарту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; башка эш төрләре); (җәен юлларны карап тоту, җәен территорияне чабу, табигый туфракта куаклар һәм вак урманлыкларны төпләү проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; башка эш төрләре);

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (Ташлы Елга авылы чишмәсен төзекләндерү, карап тоту һәм ремонтлау, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү, карап тоту һәм ремонтлау буенча башка эш төрләре);

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (зират территориясен карап тоту һәм төзекләндерү, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; башка эш төрләре);

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (яр буе зоналарын карап тоту һәм чистарту, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, башка эш төрләре).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Кәркәүч авыл җирлеге башлыгы: М.Ф.Зәйнетдинов